**Дөньякүләм «Татарча диктант» акциясенең**
**Н И Г Е З Л Ә М Ә С Е**

Дөньякүләм «Татарча диктант» акциясе «2014–2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында уздырыла башлады. Бүгенге көндә акция Татарстан Республикасының «Татар халкының милли үзенчәлеген саклау» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында уздырыла.

## Гомуми нигезләр

1. Әлеге нигезләмә 2024 нче елда «Татарча диктант» татар теленнән дөньякүләм белем тикшерү акциясенең уздыру тәртибен һәм шартларын билгели (алга таба – Акция);
2. Акция түбәндәге дәрәҗәләрдә катнашуны күз уңында тота:
   - татар телен башлангыч дәрәҗәдә белү;
   - татар телен камил белү;
3. Акция – ел саен уздырыла һәм теләге булган һәр кеше катнаша ала торган бушлай белем бирү акциясе.
4. Диктантның тексты КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының татар теле белгечләре белән Бөтендөнья татар яшьләре форумы тарафыннан билгеләнә;
5. Акцияне оештыручылар: «Бөтендөнья татар конгрессы» Халыкара берлеге Башкарма комитеты, Бөтендөнья татар яшьләре форумы, Казан (Идел буе) федераль университеты, Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты, «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе;
6. Акцияне әзерләү һәм уздыру өчен җаваплы Оештыру комитеты – Бөтендөнья татар яшьләре форумы;
7. Акция турында тулы мәгълүмат түбәндәге сайтта урнаштырыла: https://diktant.tatar.

## Акциянең максаты һәм бурычлары

Максат:

Дөнья буйлап татарларны һәм татар теле белән кызыксынучыларны берләштереп, татар телендә диктант язу.

Бурычлар:

- Татар теленә игътибарны җәлеп итү;
- Татар телен өйрәнергә кызыксынуны арттыру;
- Язуда еш күзәтелә торган хаталарны билгеләү;
- Хатасыз язу теләген уяту;
- Сәвәтлелекне арттыру;
- Татар әдәбиятын популярлаштыру;
- Тел белемен, татар теле белгечләрен һәм укытучыларын популярлаштыру.

## Акциядә катнашучылар

Акциянең асылы — Рәсәй Федерациясе һәм дөньяның төрле шәһәрләрендә бер үк вакытта барлык теләгән кешеләр өчен ихтыяри һәм бушлай уздырыла торган диктант.

Акциядә яше, җенесе, белеме, дине, һөнәре, гаилә хәле һәм кызыксынулары нинди булуга карамастан, һәр кеше катнаша кала. Моның өчен сайтка кереп, үзегез яши торган район / төбәк / илдә акция узачак мәйданчыкны табарга кирәк.

## Акцияне уздыру көне һәм вакыты

Уздыру көнннәре һәм төгәл вакыты: 2024 елның 8-10 ноябре, сәгать 10:00 (Казан вакыты буенча).

## Акцияне уздыру мәйданчыклары

Катнашучылар күп булу сәбәпле, диктант онлайн режимда, ТНВ-Татарстан, ТНВ-Планета телеканалларында һәм «Болгар радиосы»нда үткәрелә.

Шулай ук Россия Федерациясе субъектларында, чит илләрдә, Татарстан Республикасы районнарында һәм Казанның башка оешмаларында да мәйданчыклар булдырыла.

## Акцияне оештыру һәм уздыру

Акцияне оештырырга теләгән һәр кеше «Татарча диктант» сайтында теркәлә: https://diktant.tatar. Әлеге сайтта уздыру тәртибе турында мәгълүмат, бланклар һәм диктантның онлайн трансляциясенә сылтама урнаштырылачак.

**«Татарча диктант» акциясен уздыру тәртибе**:

1) Диктант узачак мәйданчыкны табу;
2) https://diktant.tatar сайтында теркәлү;
3) Диктантны тикшерүчеләрне табу;
4) Диктант язучыларны җыю;
5) Бланкларны сайттан йөкләп һәм кәгазьдә бастырып, катнашучыларга тарату;
6) Тикшереп, билгеләрне сайтка кертү.

**«Татарча диктант»ны өйдән язу тәртибе:**

1) https://diktant.tatar сайтына керү;
2) Бланкны йөкләп, кәгазьдә бастыру;
3) ТНВ-Татарстан, ТНВ-Планета телеканалларында, «Болгар радиосы»нда яки https://diktant.tatar сайты аша туры эфирны кабызу;
4) Диктантны язып бетергәч, бланкны сканлау (яисә яхшы сыйфатлы фотосурәт ясау). Сканны info@ftatar.org адресына юллау.

**«Татарча диктант»ны сайтта (онлайн) язу тәртибе:**

Диктантны телефон / планшет / санак аша язу мөмкинлеге бар.

1) https://diktant.tatar сайтында «Катнашучы» буларак теркәлү;
2) Диктант язу көнне шәхси кабинетка керү;
3) Сайттагы я ТНВ телеканалларында трансляцияне тыңлап, диктантны язу.

Бу очракта эшегез автоматик рәвештә тикшереләчәк. Билгене бер атна эчендә шәхси кабинетка кереп белә алачаксыз.

**Акциянең рәсми сайты**

Акцияне оештыру һәм уздыру вакытында мәгълүмат белән тәэмин итү өчен рәсми сайт эшләп килә.

Сайтның адресы: https://diktant.tatar

Сайт түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала: оештыручы буларак теркәлү, онлайн-катнашучы буларак теркәлү, уздыру тәртибе, psd форматындагы афиша, диктант текстлары, тикшерү критерийлары, диктант язу нокталары харитасы,

сынау, диктант язучыларның билгеләре, оештыручылар өчен рәхмәт хатлары, оештыручылар, партнерлар, элемтә мәгълүматы.

## Нәтиҗәләрне игълан итү

Диктант нәтиҗәләре Акция уздырылганнан соң 30 көннән дә соңламый сайтка урнаштырыла. Аларны бланктагы код сүзе һәм исем-фамилия буенча белеп булачак.

Акцияне уздырганнан соң, мәйданчыкны оештыручы https://diktant.tatar сайттагы шәхси кабинетына кереп, билгеләрне урнаштыра.

## Диктантны оештыручылар белән элемтә

2024 елда акциянең кураторы – Амил Нур
Элемтәләр өчен мәгълүмат: info@ftatar.org, 8(843) 236-49-66 (өст. 343).

ВКонтакте социаль челтәренә сылтама: https://vk.com/diktant.tatar